## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

19 ноябрь 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл жирлеге составына керүче Югары Чыршылы авылында 2022 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл жирлеге составына керүче Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Югары Чыршылы авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү;

2) Югары Чыршылы авылында Сабантуй, өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) Югары Чыршылы авылында балалар уен мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (ком ташу);

4) Югары Чыршылы авылында артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяу сатып алу, эшләр өчен түләү);

5) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

6) Югары Чыршылы авылы зираты өчен инструментлар (генератор, отбойный молоток) сатып алу;

7) Югары Чыршылы авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу һәм урнаштыру;

8) "Сарман" район газетасында некролог бастыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов